БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» 12 2024 ел № 305

Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган якын территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2220 номерлы карары, Татарстан Республикасының 2015 елның 6 мартындагы «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату шартларын һәм урынын өстәмә чикләү турында» 10-ТРЗ номерлы Законы нигезендә Балтач районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының 10 бүлегендә күрсәтелгән урыннарга, биналарга, корылмаларга, спорт корылмаларына якын территорияләрнең чикләрен (алга таба - объектлар) билгеләргә.

2. Объектлардан ераклыкны исәпләү түбәндәгечә башкарыла, дип билгеләргә:

- объектка якын аерымланган территория булмаганда – объект эченә (объектка) керүчеләр өчен керү урыныннан туры буенча иң кыска ара(радиус) буенча;

- объектка якын аерымланган территория булганда-аерымланган территориягә керүчеләр өчен керү урыныннан туры юлдан (радиус)иң кыска ара буенча;

- килүчеләр өчен объек эченә (объектка) яисә аерымланган

территориягә берничә керү урыны булганда-килүчеләр өчен һәр керү урыныннан туры юлдан (радиус)иң кыска ара буенча;

- биналар булган объектларны сәүдә объекты (җәмәгать туклануы объекты) белән бер бинада (төзелештә, корылмада) урнаштырганда – объектка килүчеләр өчен керү урыныннан сәүдә объектына (җәмәгать туклануы объектына) керүчеләр өчен керү урынына кадәр, барлыкка килгән җәяүлеләр юллары системасыннан чыгып, иң кыска хәрәкәт маршруты буенча.

3. Гомуми мәйданы 50 квадрат метрдан кимрәк булган җәмәгать туклануы объектларында җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган күпфатирлы йортларга якын территорияләр чикләрен күпфатирлы йорт фасадының иң якын ноктасыннан 10 метр ераклыкта туры юлдан (радиус) иң кыска ара буенча билгеләргә (килүчеләргә хезмәт күрсәтү сезонлы залы (зонасы) мәйданын исәпкә алмыйча), моңа Татарстан Республикасының 2015 елның 6 мартындагы «Алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 10-ТРЗ номерлы Законында билгеләнгән очраклар керми.

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлегенә әлеге карарны алкоголь продукциясен сату белән шөгыльләнүче шәхси эшкуарларга һәм юридик затларга җиткерергә.

5. Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органына басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә җибәрергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Галимуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов

| | | | |
|---|---|---|---|
| | теркәлгән күчемсез милек һәм хокук объектлары булган спорт корылмалары | Җәмәгать тукланув оешмалары | 30/30 |
| 5. | Вокзаллар, аэропортлар | Сәүдә предприятиеләре | 30/30 |
| | | Җәмәгать тукланув оешмалары | 30/30 |
| 6. | Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган югары куркыныч чыганакларының урнашкан урыны | Сәүдә предприятиеләре | 50/50 |
| | | Җәмәгать тукланув оешмалары | 50/50 |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «17» 12
305 номерлы карарына
кушымта

Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү

| № т/б | Объектның исеме | Сәүдә/җәмәгать туклануын оештыру (шәһәр/авыл) | Минималь ара, метрларда (шәһәр/авыл җирлеге) |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәгариф оешмалары (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш) биләгән һәм (яисә) аның файдалануындагы объектлар | Сәүдә предприятиеләре | 30/30 |
| | | Җәмәгать туклануы оешмалары | 30/30 |
| 2. | Балигъ булмаганнарны укытуны гамәлгә ашыручы оешмалар карамагындагы һәм (яисә) файдалануындагы объектлар | Сәүдә предприятиеләре | 30/30 |
| | | Җәмәгать туклануы оешмалары | 30/30 |
| 3. | Оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә юридик затлар һәм эшчәнлекнең төп (устав) төре буларак медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яисә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә бирелгән төп (устав) эшчәнлек белән беррәттән, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, юридик затлар карамагында һәм (яисә) алардан файдаланудагы объектлар | Сәүдә предприятиеләре | 2/2 |
| | | Җәмәгать туклануы оешмалары | 30/30 |
| 4. | Билгеләнгән тәртиптә | Сәүдә предприятиеләре | 30/30 |